*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________ Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2017-2018 учебный год**

**10 класс**

**I. Фразеологик гыйбарәләрне татарча языгыз. /** Напишите фразеологические обороты по-татарски (10 баллов).

1) Бить баклуши – ________________________________________________
2) Остаться на бобах – ____________________________________________
3) Бойкое перо - _________________________________________________
4) Взять за бока - ________________________________________________
5) Бросаться в глаза – ____________________________________________
6) Вариться в собственном соку – __________________________________
7) Вить веревки – ________________________________________________
8) Верить на слово – ______________________________________________
9) Голова садовая – ______________________________________________
10) Зарубить себе на носу – ________________________________________

**II.Түбәндәге шигъри юлларны кем язган? Авторларның исем һәм фамилиясен тутырып языгыз. /** Напишите полностью имя и фамилию авторов этих стихотворений. (10 баллов).

1) Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле.

**Җавап**: ________________________________________________________

2) Ишеттем мин читтә “Туган тел”не,
Халкым, нинди моңлы көең бар...
Тукаемны йотылып тыңлаганда,
Тамагымда кайнар төер бар.

**Җавап:**________________________________________________________

**III. Тотрыклы гыйбарә килеп чыгарлык итеп, исемнәрне тиешле формага куеп бәйләгез һәм мәгънәләрен аңлатыгыз /** Соединяя имена существительные, образуйте фразеологизмы и объясните значение (10 баллов).

АВЫЗ, ШҮРЛЕК, БИТ, КИБӘН, КҮЗ

Кабартма ________________________________________________________

Бал ____________________________________________________________

Ботка __________________________________________________________

Икмәк ______________________________________________________________

Ит_________________________________________________________________

**IV. Җөмләнең һәр сүзенә морфологик анализ ясагыз.** / Сделайте морфологический анализ каждого слова в этом предложении. (20 баллов)

*Дөньяда кешенең иҗади фикер эзе калган һәрнәрсә гыйбрәтле һәм матур.*

Дөньяда -__________________________________________________________

___________________________________________________________________

Кешенең - _________________________________________________________

___________________________________________________________________

Иҗади - ___________________________________________________________

___________________________________________________________________

Фикер - ___________________________________________________________

___________________________________________________________________

Эзе - _____________________________________________________________

___________________________________________________________________

Калган - __________________________________________________________

___________________________________________________________________

Һәрнәрсә - ________________________________________________________

___________________________________________________________________

Гыйбрәтле - _______________________________________________________

___________________________________________________________________

Һәм - _____________________________________________________________

___________________________________________________________________

Матур - ___________________________________________________________

___________________________________________________________________

**V. Кроссвордларны чишегез.** / Решити кроссворды (20 баллов)

**А) Бирелгән сүзләрнең синонимнарын языгыз.**/ Напишите синонимы данных слов.

**1. Вакыт -**
**2. Затлы –**
**3. Ир бала -**
**4. Матур –**
**5. Делегат -**

**6. Сандугач –**
**7. Булышчан –**
**8. Кыю -**
**9. Мәкерле –**
**10. Карасу –**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | л | | | | | |
| | | | л | | | | |
| | | | л | | | | |
| | | | | л | | | |
| | | | | л | | | |
| | | | | | л | | |
| | | | | | | | л |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | л | | |
| | | | | | | | | л | |
| | | | | | | | | | л |

**Б) Парлы сүзнең икенче кисәген языгыз. /** Напишите второй компонент парного слова.

**1. Ава -**
**2. Ватык-**
**3. Гореф-**
**4. Дөбер-**
**5. Егет-**
**6. Иелә –**
**7. Исәнлек -**
**8. Кырып-**
**9. Тормыш–**
**10. Явым-**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ә | | | | |
| | | | | к | | | |
| | | | | т | | | |
| | | | | р | | | |
| | | | | н | | | |
| | | | | | ә | | |
| | | | | | к | | |
| | | | | | | п | |
| | | | | | | | ш |
| | | | | | | | е |

**VI. Татар телендәге язу принциплары турында языгыз. Җавабыгызны мисаллар белән аңлатыгыз. /** Напишите о принципах татарской орфографии (10 баллов).

**VII. “Татар теленең Кызыл китабы булырга тиешме?” дигән темага тел сафлыгы турында 80 сүздән ким булмаган сочинение языгыз. Фикерегезне раслап, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез.** /Напишите сочинение (не менее 80 слов) о чистоте языка на тему “Нужна ли Красная книга Татарского языка?” Приведите не менее 2 довода-примера (20 баллов).

*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ __________________** **Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур (ответы)**
**2017-2018 учебный год**

**10 класс**

**I. Фразеологик гыйбарәләрне татарча языгыз. /** Напишите фразеологические обороты по-татарски (*10 баллов. 10 фразеологизмов и за каждый правильно приведенный эквивалент по 1 баллу*).

1. Бить баклуши – тырай тибү, сөрән сугу, эт сугару
2. Остаться на бобах – колау кагу, буш калу, мәхрүм калу, өлешсез калу, авыз ачып калу, авы күтәреп калу, йоклап калу
3. Бойкое перо – үткен каләм
4. Взять за бока – якасыннан алу, якасыннан тоту, якасыннан борып алу, якасыннан борып тоту, якадан алу
5. Бросаться в глаза – күзгә ташлану, күзгә ташланып тору, күзгә чалыну
6. Вариться в собственном соку – үз казанында кайнау, үз казанында үзенчә кайнау, үз маенда үзе куырылу
7. Вить веревки – кырыкка бөгү
8. Верить на слово – коры сүзгә ышану
9. Голова садовая – ачык авыз, мәми авыз
10. Зарубить себе на носу – колакка киртеп кую, борынгы киртләп кую, колагына киртләү, маңгайга язып кую

**II.Түбәндәге шигъри юлларны кем язган? Авторларның исем һәм фамилиясен тутырып языгыз. /** Напишите полностью имя и фамилию авторов этих стихотворений. (10 баллов. 2 автора. За каждый правильно приведенный ответ по 5 б).

1) Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле.

**Җавап**: **Нажар Нәҗми**

2) Ишеттем мин читтә “Туган тел”не,
Халкым, нинди моңлы көең бар...
Тукаемны йотылып тыңлаганда,
Тамагымда кайнар төер бар.

**Җавап: Шәүкәт Галиев**

**III. Тотрыклы гыйбарә килеп чыгарлык итеп, исемнәрне тиешле формага куеп бәйләгез һәм мәгънәләрен аңлатыгыз** / Соединяя имена существительные, образуйте фразеологизмы и объясните значение (10 баллов. 5 примеров. За каждый ответ: 1 *балл - за краткий верный ответ + 1 балл – за верное толкование.*).

**Кабартма бит – кабарып, түгәрәкләнеп торган, симез бит.**
**Бал авыз – ягымлы сүзле, татлы телле кеше турында.**
**Ботка күзе – ботканың уртасында кашык белән ясалган май чокыры.**
**Икмәк шүрлеге – авыз**
**Ит кибәне – бик ямьсез симергән, ян-якка бүселгән кеше.**

**IV. Җөмләнең һәр сүзенә морфологик анализ ясап языгыз.** / Сделайте морфологический анализ каждого слова в этом предложении. *(20 баллов. За каждый полный верный ответ по 2 балла).*
*Дөньяда кешенең иҗади фикер эзе калган һәрнәрсә гыйбрәтле һәм матур.*

Дөньяда - ________________________________________________

________________________________________________

Кешенең - ________________________________________________

________________________________________________

Иҗади - ________________________________________________

________________________________________________

Фикер - ________________________________________________

________________________________________________

Эзе - ________________________________________________

________________________________________________

Калган - ________________________________________________

________________________________________________

Һәрнәрсә - ________________________________________________

________________________________________________

Гыйбрәтле - ________________________________________________

________________________________________________

Һәм - ________________________________________________

________________________________________________

Матур - ________________________________________________

________________________________________________

**V. Кроссвордларны чишегез.** /Решити кроссворды (20 **баллов. За каждое верно угадонное и написанное слово по 1 баллу)**

**А) Бирелгән сүзләрнең синонимнарын языгыз./** Напишите синонимы данных слов.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | л | | |
| | | | л | |
| | | | л | |
| | | | | л |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | л | | | | | |
| | | | | | л | | | | |
| | | | | | | | л | | |
| | | | | | | | л | | |
| | | | | | | | | л | |
| | | | | | | | | | л |

**Ответы**

1. **Вакыт - мәл**
2. **Затлы - асыл**
3. **Ир бала - угыл**
4. **Матур - гүзәл**
5. **Делегат - вәкил**
6. **Сандугач - былбыл**
7. **Булышчан - ярдәмчел**
8. **Кыю - тәвәккәл**
9. **Мәкерле - хыянәтчел**
10. **Карасу - каратуткыл**

**Б) Парлы сүзнең икенче кисәген языгыз. / Напишите второй компонент парного слова.**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ә | | | | |
| | | | | к | | | |
| | | | | т | | | |
| | | | | р | | | |
| | | | | н | | | |
| | | | | | ә | | |
| | | | | | к | | |
| | | | | | | п | |
| | | | | | | | ш |
| | | | | | | | е |

**Ответы:**

1. **Ава-түнә**
2. **Ватык-сынык**
3. **Гореф-гадәт**
4. **Дөбер-шатыр**
5. **Егет-җилән**
6. **Иелә-бөгелә**
7. **Исәнлек-саулык**
8. **Кырып-себереп**
9. **Тормыш-көнкүреш**
10. **Явым-чәчемле**

**VI. Татар телендәге язу принциплары турында языгыз. Җавабыгызны мисаллар белән аңлатыгыз.** / Напишите о принципах татарской орфографии (10 баллов. *2 балла - за краткий верный ответ, 8 баллов – за верное обоснование с примерами*).

Әдәби телдә дөрес язу нормалары һәм кагыйдәләре җыелмасын орфография дип йөртәләр.

Татар орфографиясе берничә принципка нигезләнә:

Фонетик принцип. Бу - сүзләрне ишетелгәнчә язу дигән сүз, һәм ул безнең телдә төп принцип булып санала. Мәсәлән, кайчакта сүзгә кушымча ялганганда, сүзнең соңгы авазы үзгәрә, һәм ул язуда да күрсәтелә:
ак - агы    китап - китабы    кара - карабрак һ.б.

Морфологик принцип. Бу - сөйләмдә кулланганда, сүзләрнең кайбер авазлары үзгәрсә дә, аларны язуда, үзгәртмичә, беренчел морфологик төзелеше ничек булган, шулай язу дигән сүз. Мәсәлән, ун һәм бер сүзләре янәшә килсә, [умбэр] дип әйтелә, унбер дип языла; [һишшыксез] дип әйтелә, һичшиксез дип языла; [чәчәгата] дип әйтелә, чәчәк ата дип языла.

График принцип. Бу - алынма сүзләрне шул тел орфографиясендәгечә язу дигән сүз. Мәсәлән, татар телендә рус теленнән алынган сүзләр рус теле орфографиясечә языла: морфология, лексикология, эволюция, бизнес, менеджер...

Тарихи-традицион принцип. Бу - сүзләрне, хәзерге телдә ничек әйтелүенә карамастан, борынгы чорда ничек язылган, шулай язу дигән сүз: сурәт - [сурәт].

Экономия принцибы. Бу - язу барышында вакытка һәм урынга экономия ясау өчен, сүзләрне кыскартып язу дигән сүз. Телдә еш кулланыла торган һәм күпләргә таныш кушма атамалар андагы үзләрнең баш хәрефләрен генә язу юлы белән кыскарталар: Казан дәүләт университеты - КДУ, Берләшкән Милләтләр Оешмасы - БМО. Еш очрый торган сүзләр, атама булмаса да, кыскартылырга мөмкин: һәм башкалар - һ.б. Кайбер кушма атамаларда беренче сүзнең - баштагы өлеше, башка сүзләрнең баш хәрефе генә языла: КамАЗ, АлАЗ. Кушма сүзнең соңгысы - тулы килеш, баштагылары кыскартылып язылырга да мөмкин: драмтүгәрәк, райүзәк.

**VII. “Татар теленең Кызыл китабы булырга тиешме?” дигән темага тел сафлыгы турында 80 сүздән ким булмаган сочинение языгыз. Фикерегезне дәлилләп, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез.** / Напишите сочинение (не менее 80 слов) о чистоте языка на тему “Нужна ли Красная книга Татарского языка?” Приведите не менее 2 довыда – примера (20 баллов)___

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |

***Исправления не допускаются***